Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№34 (47)

29 ноябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**26 НОЯБРЬ КӨННЕ** КФУ студентлары һәм укытучылары «Биоинженерия» үзәге директоры **КОНСТАНТИН СКРЯБИН ЛЕКЦИЯСЕН ТЫҢЛАДЫЛАР**. Галим «Үзенең геномын белү кешегә ни өчен кирәк»леген аңлатты. Константин Скрябин әйтүенчә, бүгенге көндә Россиядә кешенең геномын ачыклый торган 12 суперкомпьютер бар.

• • • •

Шул ук көнне вузга кадәр, гомуми һәм педагогик белем бирү эшләре буенча КФУ ректоры киңәшчесе **ЛЮДМИЛА НУГУМАНОВА IT ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘТИ-ӘНИЛӘРЕ БЕЛӘН КҮРЕШТЕ**. Людмила Николаевна үзенең эшчәнлегендә төп юнәлеш булып, IT лицейда кураторлыкны атады. Ә әти-әниләрдән балаларының ни дәрәҗәдә канәгать булуларын һәм аларның тәкъдимнәрен белеште. Җыелышта иң актуаль сорауларның берсе IT-лицейга укырга кызларны кайчан кабул итә башлавы турында булды. Сорауга уңай җавап бирелде: 2013 елның сентябреннән лицейда кызлар да белем алачак.

• • • •

**27 НОЯБРЬ КӨННЕ** Казан университеты студентлары **ШЛЮМБЕРЖЕ ПРОГРАММАЛАРЫНА** керү мөмкинлегенә ия булды. Лицензияле укыту программалары фәнни-тикшеренү һәм укыту максатларында файдаланылыр дип көтелә. Лицензия алу турында сүз җәй көне үк кузгатылган иде һәм менә көз ахырында ул гамәлгә ашырылды.

• • • •

КФУның Чаллы филиалы студентлары «Кояшкай» реабилитация үзәгендә үткәргән **ТӨРЛЕ УЕННАР, КЫЗЫКЛЫ КОНКУРСЛАР, ҖЫРЛАР БАЛАЛАР КҮҢЕЛЕНӘ БИК ХУШ КИЛДЕ**. КФУ волонтерлары һәр балага истәлекле бүләкләр һәм тәмле күчтәнәчләр тапшырды.

• • • •

**27 НОЯБРЬ КӨННЕ КФУ**га **ВЬЕТНАМ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ КИЛДЕ**. Кунаклар уку йортыбызның тарихы, актлар залы, мемориаль аудитория, заманча җиһазлар белән танышты. Очрашуның төп максаты – Вьетнам дәүләте белән хезмәттәшлек күпере салу. Казан университетыннан 20 студенты Вьетнам республикасында белем ала. Шуңа да карамастан КФУ бу шәрык илннән бер генә вузы белән дә хезмәттәшлек итми. Киңәшмә барышында әлеге проблеманы хәл итү юллары каралды.

• • • •

Чаллы мэры **ВАСЫЙЛ ШӘЙХРАЗЫЕВ** КФУның автошәһәрдәге филиалында белем алучы **СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Шәһәр башлыгы үз чыгышында төрле мәсьәләләргә игътибар бирде, студентларга киңәшләрен җиткерде, тәҗрибәсе белән уртаклашты. Беренче чиратта, мэр Чаллы яшьләренең кайсы җәмәгать урыннарында аеруча еш булуы турында белеште. Алга таба ике вузның берләшү (ИНЭКА һәм КФУ филиалы) мәсьәләсен карады. Яшьләрне бигрәк тә универсиада алдыннан актив булырга дәште.

• • • •

Быел Татарстан Республикасы мәгълүмати технологияләр өлкәсендә тикшеренүләр алып барыр өчен, КФУның **МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР** һәм **СИСТЕМАЛАР ЮГАРЫ МӘКТӘБЕНӘ МАХСУС ГРАНТ – БЕР МИЛЛИОН ДОЛЛАР БҮЛЕП БИРГӘН**. Финанслауның төп максаты – бу өлкәдә алып барыла торган тикшеренүләрне киңәйтү һәм көчәйтү өчен, республикага бөтен дөньядан актив галимнәрне җәлеп итү.

• • • •

**28 НОЯБРЬ КӨННЕ** УНИКСның кече залында «Глобаль белем бирү» программасы тәкъдим ителде. Стратегик инициатива агентлыгы вәкиле **АЛЕКСАНДР РУСИНОВ** аның турында тәфсилләп **СӨЙЛӘДЕ**. Әлеге чара «Яшь профессионаллар» проекты кысаларында үткәрелә. Программаның үзенчәлеге булып алдынгы югары уку йортына мөстәкыйль рәвештә укырга керү мөмкинлеге тора. Һәр теркәлергә теләгән кеше программаның сайтында уку йортына керүне раслый торган документны күрсәтергә тиеш.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Наилә Бадыкшанова фотолары



# Идел буе яңарышлар юлында

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

28 ноябрь көнне Казан федераль университеты Идел буе федераль округы уку йортларының ректорларын үзендә җыйды. Чарада сигез югары уку йортының ректоры чыгыш ясап, бүгенге көндә иң актуаль проблемаларның чишү юлларын эзләде.

Без зур үзгәрешләр чорында яшибез һәм бу яңалыклар тормышыбызның барлык өлкәләренә дә кагыла. Иң мөһиме, кешеләрнең бу процесска мөмкин кадәр тизрәк һәм җиңел җайлашуы. Чарага килгән югары уку йортлары ректорлары да шушы мәсьәләгә кагылышлы әңгәмә корды. Инновацион эшчәнлек турында сүз алып барганда, кайбер уку йортларын үзгәртеп төзергә кирәк дигән фикер дә яңгырады. Кызганыч, бүгенге көндә югары уку йортлары арасында көчсезрәкләре дә бар. Алар үзләре генә яңа икътисади тормышның тиешле дәрәҗәсенә күтәрелә алмаячак. Андыйларга ярдәм йөзеннән «көчле» уку йортына «көчсезрәген» кушу күздә тотыла.

Казан федераль университеты – үзгәртеп кору нигезендә барлыкка килгән яңа фәнни-мәгариф структура тәҗрибәсенең бер үрнәге. Моны үзенең чыгышында КФУ ректоры Илшат Гафуров та билгеләп: «Үзгәртеп кору процессы бервакытта да җиңел генә бармый. Аның авыр нәтиҗәләре югары уку йортына, коллективка, хәтта кайбер гаилә әгъзаларына да кагыла», – диде. И.Гафуров университетның яңа структурасын аңлатты, яңа проектларның матур нәтиҗәләре белән таныштырды.

РФ Президентының Идел буе федераль округында тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Галина Изотова: «Идел буе федераль округы илебездә сәнәгать потенциалы буенча беренче урында тора. Шулай да, без үзебез теләгән позицияләрдә түгел. Шуңа күрә, әлеге кысалардан чыгу өчен, дөрес юлларны эзләргә, яңалыклар кертергә кирәк», – дип белдерде.

Җыелышта Н.М.Лобочевский исемендәге Түбән Новгород университеты ректоры Евгений Чупрунов, Н.Г.Чернышевский исемендәге Саратов дәүләт университеты ректоры Леонид Коссович, Оренбург дәүләт университеты ректоры Владимир Ковалевский, Пермь милли политехник тикшеренү университеты президенты Василий Петров, М.Т.Калашников исемендәге Ижевск дәүләт техника университеты ректоры Борис Якимовичлар чыгыш ясады.

«Бүгенге җыелышта яңалыкның тормышыбызга ничек үтеп керүен аңладык. Кызык бит: моның турында китаплар, билгеле бер конструкцияләр юк, ә без инде аларны гамәлдә куллана алабыз», – дип фикерләре белән уртаклашты Идел буе Федераль округы югары уку йортларының ректорлары Советы рәисе, Н.М.Лобочевский исемендәге Түбән Новгород университеты президенты Роман Стронгин.

Һәр яңалыкның уңай һәм тискәре яклары бар. Бу проектларның да файдасы зыяннынан күбрәк булыр дип ышанабыз.

## • Сәяхәттән кайткач

# Хезмәттәшлек нәтиҗәләре

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче



28 ноябрь көнне Теләче районы зур кунаклар кабул итте. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы үткәргән җыелышта КФУның абитуриентлар өчен эшли торган порталы тәкъдим ителде.

Муниципаль органнарның мәгариф идарәсе җитәкчеләренең республикакүләм җыелышында Мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов катнашты. Җөмһүриятебездән җыелган бер төркем делегация пленар утырыш башланганчы, нинди дер проблема, планнар турында сөйләшкәнче, халкыбызга зур шәхесләр бүләк иткән Теләче районының күп кенә объектлары белән танышты. Беренче булып, быел гына яңа бинага күчкән Иске Җөри мәктәбенә бардык. Биредә укучылар өчен мөмкинлекләр бик зур. Сыйныф бүлмәләре заманча технологияләр белән җиһазландырылган, зур, якты, чиста. Укучыларның да белемгә омтылышы әллә кайдан сизелеп тора.

Теләче мәктәбе республика күләмендә тормышка ашырыла торган капиталь ремонт программасына эләккән. Биредә яшь буынны мөстәкыйль, иҗади яктан актив һәм заман шартларына яраклаша торган шәхесләр итеп тәрбияләүне максат итеп куялар. Әйтергә кирәк, мәктәпне тәмамлаган укучыларның югары уку йортларындагы күрсәткечләре дә яхшы.

**Ахыры 2нче биттә.**

● Бездә кунак бар

# Жорес АЛФЕРОВ: «Россия - оптимистлар иле!»

Рифат СӘЛАХ

**27 ноябрь көнне Физика институтына «Оптоэлектроника өчен гетероструктура. Тарихы һәм хәзерге тенденцияләр» темасына лекция укыр өчен, Нобель бүләге лауреаты, РФ Дәүләт Думасы депутаты, галим Жорес Алферов килде.**


Руслан Гыйниятов фотосы

Физика фәнен мәктәптә генә укучыларга бу лекцияне тулысынча аңлап җиткерү мөмкин дә түгел. Бигрәк тә, галим ярымүткәргечләр ярдәмендә лазер ясау тарихын тәфсилләп сөйләгәндә. Ни хикмәт, аудиториядә утыручы студент-физиклар авыз ачып тыңладылар, кайбер җөмләләрне кәгазь битенә теркәп үк бардылар. Урындыклар гына түгел, аудиториянең баскычларында да утырган егетләр-кызлар тын калган, хәтта көн яктылыгы лампаларының җуылдавын ишетәсең...

Лекциянең темасы да очраклы рәвештә сайланмаган. Ярымүткәргечләрдән ясалган лазерларга быел илле ел икән. Беренче лазерлар аерым бер шартларда гына эшләгән. Алферов төркеме бу ачышны камилләштерергә алынган. 1967 елда бүлмә шартларында эшли торган лазерны дөньяга чыгарган алар. Жорес әфәнде бу ачышны бәхетле очрак дип атый. Химия галиме Дмитрий Третьяков ярымүткәргечләрне өйрәнү өлкәсендә шөгыльләнгән төркеменнән аларга кучкәч, буачыш үзен озак көттерми. Кучүнең сәбәбе дә бүгенге көн өчен кызыклы. Третьяков җитәкчесенең кызына өйләнгән икән. Ул вакытта туганнарда бер-берсен тарту гадәте булмаган, ә, киресенчә, һәркем аерым эшләргә тырышкан. Жорес Алферов бүгенге туганнарны бер урынга җыя торган вәгъяятьне өнәп бетерми.

Аларга бәйсез рәвештә, ләкин ике айга соңрак Америка галимнәре дә бүлмә температурасында эшли торган лазер уйлап таба. Галим сүзләренчә, алтмышынчы-җитмешенче елларда СССР-АКШ арасында салкын сугыш барганга карамастан, галимнәр дуслык җепләрен өзмәгән.

Лазер турында АКШта чыгыш ясагач, өлкәсез эшли торган лазер ясау буенча галимнәр арасында ярыш башланган. Бу бәйгедә дә илебез җиңеп чыккан. Ж.Алферов җитәкчелегендәге галимнәр төркеме АКШ коллегаларыннан бер айга алданрак өлгергән.

Алферов фикеренчә, фәндәге проблемалар СССР таркалгач башлана: «Ул елларда икътисад системасы җимерелү сәбәпле, фәнгә бирелгән акча егерме мәртәбә кимеде. РФАның Физика институты Читилләр белән элемтә нык булганга гына исән калды. СССРны унбишкә бүлделәр бит. АКШтагы коллегаларыма да, әгәр илегезне унбиш бәйсез дәүләткә бүлсәләр, нишләр идегез, дим».

Лекциядән соң, Алферов катнашучыларның сорауларына җавап бирде. Тыңлаучылар галимнең атом-төш объектларына уңай мөнәсәбәте турында ишеткән. Жорес әфәнде моны кире какты: «Атом-төш станцияләрен һич кенә дә якламыйм. Бу проект искерде инде», – ди ул. Шулай да, дөньяның шушы килеш сакланып калуына атом-төш коралларын уйлап чыгаручы Курчатов, Сахаров кебек галимнәргә ихтирамы зур аның. «Атом-төш коралын кулланып илебезне юк итәргә теләүчеләр булганы хәзер сер түгел», – ди Алферов. Илебез фәне яңадан дөньяда элекке урынын кайтаруына Жорес әфәнденең өмете сүнмәгән. «Россия – оптимистлар иле. Пессимистлар моннан күптән китеп бетте инде», – ди ул уенын-чынын бергә кушып.

КФУның Физика институты директоры Альберт Аганов әйтүенчә, мондый лекция икенче ел рәттән уздырыла. Жорес әфәндене киләсе елга да университетыбызда күрергә насыйп булсын иде!

● Остаханә

# Бәхәс тумасын, дисәң...

Динара ЗИННӘТОВА,
хәбәрче

**27 ноябрь көнне КФУ һәм «Яшь карьерист» компанияләр төркеме тарафыннан оезрләнгән «Катлаулы коммуникацияләр яки эштә конфликт булдырмау юллары» дип исемләнгән уникаль мастер-класс узды.**

Остаханәне дөнья күләмендә эшләп килүче «Анхойзер Буш-ИнБев» оешмасының Россиядәге бүлеге – Sun InBev Russia акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре үткәрде. Алар конфликт барлыкка килүнең төп сәбәпләрен аңлатты, эш урынында аңлашылмаучанлык тудырмау өчен нишләргә кирәклеге турында сөйләде. Мисал итеп, «Мне бы в небо» фильмыннан өзекләр күрсәттеләр. Баксаң, һәр конфликтның нигезе – кешеләрнең тегеяки бу эшне башкару өчен туган мотивларның төрлелеге икән. Әңгәмәдәшең белән уртак тел табу өчен, аның теләкләрен, максатларын аңлап алырга кирәк. Әйтик, җитәкче хезмәткәренә нинди дә булса эш башкарырга куша һәм эшне уңышлы башкарган очракта, аңа карьера үсеше вәгъдә итә. Ләкин хезмәткәрне әлеге тәкъдим кызыксындырмаска мөмкин, чөнки ул, гаилә кешесе буларак, үз урыны белән тулысынча канәгать. Күбрәк вакытын гаиләсе белән үткәрергә тели, ди. Бу очракта җитәкчегә, хезмәткәренең мотивларын аңлап, аны башка нәрсә белән кызыксындырырга, әйтик, яхшы эш нәтиҗәләре өчен өстәмә ял көннәре яки отпуск вәгъдә итәргә кирәк. Ул вакытта хезмәткәр үз эшен нәтиҗәлерәк һәм сыйфатлырак башкарачак.

Кешеләрнең тегеяки бу мотивларын ничек аңларга соң? Моның өчен тирә-яктагыларны игътибар белән тыңларга гына кирәк. Әңгәмәдәшеңнең ни теләгәнен чамалап, аның мәнфәгатьләрен исәпкә алсаң, уртак тел табу үзе кыенлык тудырмаячак.

Мастер-класста катнашучыларга Томас Килман методикасы буенча төзелгән конфликт ситуациясендә үз-үзеңне ничек тотарга өйрәнү өчен тест үтәргә дә тәкъдим иттеләр. Бу сораштыру һәр кешенең бизнес өлкәсендә нинди вазыйфа башкара алуын билгеләргә ярдәм итәргә мөмкин. Шуңа күрә мастер-класска килмәүчеләргә бу тестны үтәргә киңәш итәр идем. Яныңдагы кешеләрне яхшырак аңлар өчен, әлеге дә баягы «Мне бы в небо» фильмын карау да комачау итмәс.

Мастер-класс дүрт сәгать дәвам итте. Шулай да вакытның үтүе бөтенләй сизелмәде дә. Мондый чара яшьләргә генә түгел, һәркемгә дә файдалы булыр. Үз теләкләребезне генә исәпкә алмыйча, башкаларның фикеренә дә колак салу – нәтиҗәле хезмәттәшлекнең һәм кешелекле мөнәсәбәт коруның төп нигезе.

● Сәяхәттән кайткач

# Хезмәттәшлек нәтиҗәләре

Башы 1нче биттә.

Бу мәктәпнең тагын бер уңышы – Казан федераль университеты белән хезмәттәшлек итүе. Кунаклар игътибарына КФУның Кабул итү комиссиясе сәркатибе Сергей Ионенко укучыларны БДИга әзерләү өчен эшли торган Порталны тәкъдим итте. Уку йортының «UNIVER TV» каналы белән ун предмет буенча эшләнгән 20 видео-дәрес башка район җитәкчеләрендә дә зур кызыксыну уятты.

Сәламәт тәндә – сәламәт акыл булганын биредәге халык яхшы аңлый икән. Мәктәп белән янәшә генә урнашкан «Батыр» спорт комплексы гөрләп эшли. Телисең икән, футбол, волейбол, баскетбол, шахмат уйна, кул көрәше, милли көрәш белән шөгыльлән. Иң мөһиме, теләк кенә булсын!

Теләче районы бүгенге көндә актуаль темаларның берсе Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча да горурлана ала. Пленар утырышта шушы мәсьәләгә кагылышлы сораулар күтәрелде. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә БДИ – каршылыклы фикерләр тудыра торган иң зур мәсьәлә. Чыгышларда тәҗрибә уртаклашу белән бергә, күп кенә теләк-тәкъдимнәр дә яңгырады. Казан федераль университетының вузга кадәр, гомуми һәм педагогик белем бирү эшләре буенча ректор киңәшчесе Людмила Нугуманова «Казан федераль университетының Татарстан Республикасындагы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны БДИга әзерләү буенча электрон программасы» дигән темага чыгыш ясады. Бүгенге көндә порталда 307 меңнән артык кеше теркәлгән. Биредә белем дәрәҗәсен сынап карау белән беррәттән, төбәкара олимпиадаларда, төрле тикшеренүләрдә катнашырга, иң мөһиме, КФУ эшчәнлеге белән танышырга мөмкин. «Сезгә сыйфатлы белем бирергә кирәк булса, безгә уңышлы абитуриентлар кирәк. Шуңа күрә хезмәттәшлекне тагын да арттырсак иде», – диде Людмила ханым.

Бүгенге заманда конкурентлыкка сәләтле укучыларны тәрбияләү – иң төп максатларның берсе. Бөтен кеше дә галим, язучы йә артист була алмый, ләкин һәркем үз хезмәтендә рәссам дәрәҗәсенә җитәргә, аны иң якты төсләр белән буярга тиеш.

● Аталар сүзе - акылның үзе

# Халык энҗеләрен җыйганда

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче



**Һәр елны икенче курсны тәмамлаган студентлар җәй айларында үзләре яшәгән төбәкләрдә фольклор практикасы узалар. ФСИның татар филологиясе бүлегендә студентларның фольклор практикасы нәтиҗәләре буенча оештырылган «Халык энҗеләрен җыйганда...» дип аталган чараны мин генә түгел, килгән барлык кунаклар рәхәтләнеп карап утырды...**

Татар әдәбияты тарихы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Луиза Җәмалиева оештыра торган әлеге кичә башкаларыннан үзенчәлеклерәк тә булды кебек. Моның сәбәбе фольклор практикасының географиясе шактый киң булу белән бәйледер, мөгаен. Хәзерге вакытта өченче курста укучы 41 студент Татарстанның төрле районнарында һәм Русиянең татарлар күпләп яшәгән башка төбәкләрендә, аерым алганда, Оренбург өлкәсе Бакай авылында, Пенза өлкәсе Кикин авылында, Мари-Эль Республикасы Портнәр авылында, Киров өлкәсенең Иске Пенәгәр авылында, Башкортстанның Кушнаренко районында практика узган.

Студентлар үзләренә информант буларак өлкән буын кешеләренә мөрәҗәгать иткән. Кагыйдә буларак, алар үзләре яшәгән заман турында сөйли. Чор үзгәргән саен, нинди жанрларга игътибар кимесә дә, халык иҗаты һәрвакыт халык белән бергә яши. Әйтергә кирәк, студентлар фольклоры – аерым өйрәнүгә таләп итә торган өлкә. Бу хакта студентлар бик матур видеоролик төшергән. Студент тормышының «сират күпере» – имтиханнар сессиясе хакында кечкенә метражлы фильм бик уңышлы килеп чыккан. Монда студентларның төрле сынамышлары, ышанулары, мәзәкләре – бар да бар.

Бәйрәмгә килгән кунаклар өчен быел тагын бер кызыклы яңалык бар иде! Ул элеккеге авыл өйләре кебек бизәлгән почмакта кызларның шушы кыска вакыт аралыгында бер оекбаш бәйләп бетерүләре булды! Димәк, студентларыбыз тырыш кына түгел, ә алтын куллы да икән. Луиза апаның тагын бер үзенчәлекле гадәте бар: имтиханга кадәр кызлардан кульяулык чигү осталыкларын тикшереп карый. Бу эшләр дә күргәзмәгә куелган иде.

Материаллар шулкадәр күп җыелган ки, бер дәрес кысаларында гына аларның барысын да күрсәтеп бетерү мөмкин түгел. Мөгаен, иң-иң кызыклыларны гына күрсәтү өчен, студентларга энтузиазм һәм барлык уйлау сәләтен эшкә җигәргә туры килгәндер. Бала туу, никах туе һәм кешене соңгы юлга озату, хәрби хезмәткә китү белән бәйле мәгълүматлар да аерым музыкаль күренешләрдә тамашачыларга кызыклы формада җиткерелде. Студентлар гаилә йолаларына караган мәгълүматларны да бик теләп туплаган.

Җыелган материаллар арасында халык иҗаты һәм язма әдәбият әдәбиятны бергә үрелгән. Аеруча кызларның күңел дөньясын күзәтергә мөмкинлек биргән истәлек дәфтәрләре дә шактый. Алар да халык иҗатының аерым чорларда ни дәрәҗәдә популяр булуын күзәтергә ярдәм итә.

Татар филологиясе бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре докторы, профессор Флера Сәйфулина: «Практикага йомгак ясау бу әле халык иҗатын өйрәнү тәмамланды дигән сүз түгел. Әлеге материаллар фәнни мәкаләләр, курс һәм квалификация эшләре язганда файдаланылыр», – дигән тәкъдимен җиткерде. Бу бәйрәмнән дә һәркем үзенә рухи байлык, ниндидер рәхәтлек хисе алды. Бердәм рәвештә практика эстафетасын быелгы икенче курсларга тапшырдык!

● Юбиляр

# Фидакарь галим

Бу көннәрдә университетыбыз галиме Мансур Хөснетдинов 75 еллык олуг юбилеен билгеләп үтә.

Үзен яшьтән үк математик гыйлем биргүгә багышлаган кеше ул. Ә укытучы булу – гомерлеккә белем илендә яшәп калу дигән сүз. Аның өчен исә гаять зур сабырлык, эш сөючәнлек, пөхтәлек, җыйнаклык һәм тагын бик күп шундый сыйфатларга ия булу таләп ителә. Халык телендә дә, укытучы булып туарга кирәк, дигән гыйбарә йөри. Димәк мондый олуг исемгә лаек булу өчен күп укырга, педагогик осталыгыңны даими арттырырга, камилләштерергә кирәк. Әлбәттә, яшьләрне ярату, алар белән аралашудан тәм табу, бөтен гомереңне шул изге эшкә багышлау зарур.



Моннан 75 ел элек Чүпрәле районының Кече Чынлы авылында дөньяга килгән малай мәктәптә чагында ук математикага тартыла. Шул мавыгулар Казан дәүләт педагогика институтына китерә аны. Югары уку йортын тәмамлагач та, туган ягы - Иске Шәйморза мәктәбендә математика укыта башлый. Армия сафларына алынып, солдат боткасын да татырга туры килә. 1964 елда хезмәт итеп кайткач, аны үзе укыган институтка чакыралар. Ул биредә математика укыту белән беррәттән, аспирантурада да белем ала. Аны бары тик яхшы билгеләренә генә тәмамлый.

Мансур Зыятдинович математика фәненә мөкиббән булуын аңлый. Үз фәнен тирәнтен үзләштерә, аны укыту методикасын да яңарта, киләчәк буын математика укытучыларын тәрбияләүнең үзенчәлекле ысулларын булдыра. 1970 елда аспирантураны тәмамлагач, яшь галим алгебра кафедрасына өлкән укытучы итеп раслана. Фәнни эшчәнлеген дәвам иттереп, ул мәктәп һәм югары уку йортларында математика укыту хакында йөзләгән фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләрен бастырып чыгара. Шул эшләре өчен аңа 1993 елда доцент дәрәҗәсе бирелә. Ул – татар телендә басылган математика терминнарының аңлатмалы сүзлеге, шулай ук татар телендә нәниләр өчен өч кисәктән торган математикадан уку кулланмасы авторларының берсе.

Мансур әфәнде беренчеләрдән булып, университетта алгебра фәнен татарча укыта башлый. Аның тырышлыгы, эчкерсез ярдәме белән шушы узган вакыт эчендә меңнәрчә егет һәм кыз педагогика университетын тәмамлады. Татарстан һәм Идел буе өлкәләренең кайсы гына төбәген алма, Мансур Хөснетдиновның элеккеге шәкертләренә тап буласың. Алар инде үзләре дә балалар укыта, югары җитәкче урыннарда эшли.

**Ә.Н.Хуҗиәхмәтов,** профессор, педагогика фәннәре докторы, РАГН академигы,
**Р.Р.Насибуллов,** доценты, педагогика фәннәре кандидаты

***Илнар Митначев фотосы***

● Тамашадан соң

# Без саташмадыкмы икән?

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Филология һәм сәнгать институты бинасының актлар залы яңәдән кунаклар каршылады. Моның сәбәпчесе – «Мизгел» яшьләр халык театры. Туфан Миңнуллин истәлегенә багышлап, яшь артистлар узган пәнҗешәмбе көнне спектакльне тамашачыларына тәкъдим итте.

Сәхнәләштереләсе пьеса булып, Туфан Миңнуллинның «Саташу» драмасы очраклы рәвештә генә сайланмаган. «Мизгел» яшьләр халык театры режиссеры Марсель Җаббаров бөек драматургыбызга аның әсәрен куярга сүз биргән булган һәм ул вәгъдәсен үтәде. Тамашачылар арасында Туфан абыйның хәләл җефете, актриса Нәҗибә апа Ихсанова, каләмдәшләре, якыннары да бар иде.

Әсәр инде беренче тапкыр гына сәхнәләштерелмәсә дә, аның белән күпләр таныш булсалар да, ул үзенең тәэсирен югалтмый. «Артистлар драманың эчтәлеген тирән аңлаганнар һәм шуны дөрес, төгәл итеп, барлык шартлы алымнарны да урынлы файдаланып, сәхнәгә менгерә алдылар. Минемчә, М.Җаббаровның иң зур казанышы ул – Т.Миңнуллинның стилен саклап, аның фикерен тулы итеп, үзгәртмичә җиткерә алуы. Бу очракта режиссер үзе дә автор фикерен яңгыратучы ролен башкарды», – дип фикерен уртаклашты филология фәннәре кандидаты, доцент Гөлфия Гайнуллина.





Рамил Газизов фотолары

Әсәр фәлсәфи рухта иҗат ителгән. Анда аталар белән балалар арасындагы мәңгелек аңлашылмаучанлык, рухи кыйммәтләрнең юкка чыгуы, кешеләрнең ак белән караны аермый башлавы сурәтләнә. Нәкъ менә фәлсәфә көчле булганга күрә, аның эчтәлеген тулысы белән ачып бетерү бик җиңел түгел. Әмма монда артистларның профессиональ осталыклары, талантлы остазлары ярдәмендә беренче карашка катлаулы булган драманы тамашачылар җиңел кабул иткәннәр: «Мизгел» күңелле мизгелләр бүләк итте! Артистларның үз-үзләрен тотышлары, рольгә кереп уйнаулары таң калдырды. Әсәрне укымыйча бармагыз, аңлыйсы кыен дисәләр дә, драма бер дә авыр тәэсир калдырмады. Туфан абыйның теле халыкчан булгангадыр инде», – ди ФСИ студенты Гөлчәчәк Хөснуллина.

Театрда кичергән мизгелләр бик үк күңелле булмаса да, күпләрне уйга салды. Тамашачыларның күңелләре тулып, күзләре яшькә чыланды. Безнең халкыбыз шулай бит инде ул: аңа театрда йә кычкырып көләргә, йә утырып еларга булсын. Шундый очракта гына әсәргә уңышлы дип бәя бирәбез. Ә бу спектакльне карагач, ирексездән уйга каласың. Без дә саташмадыкмы икән?

● Хис илендә

# Өч төрле күз...

**Алсу НУРГАТИНА,**
татар журналистикасы бүлеге

Галәмгә көз ничек килә? Җәй көне мәктәпне сагынып йөгергән балаларның алъяпкыч канатларына кунып-мы, иртәләрен кырау кискән чәчәкләрнең җиргә коелган таҗлары белән уйнапмы, яшел шәлен алтын төскә алыштырган каеннар кәүсәсенә сарылыпмы, әллә...

Ә мин быел өч төрле көзне каршы алдым.

Беренчесе – Белемле көз. Мәктәпне тәмамлавыма быел нәкъ бер ел булды. Ул чаклар бик сагындыра, шуңа да белем йортыннан сукмакларым бер дә өзелми. Мәктәбебездә үткәрелгән «Сары яфраклар» бәйрәмендә әдәби сорауларга җавап биреп, үз төркемнәре өчен барсына да әзер булган җанатарлар, гадел булырга тырышкан хөкемдарлар белән бергә белемле көз килде.

Икенчесе – Самими көз. Дөньядагы иң самими затлар, әлбәттә, сабыйлар. Мин көзне икенче тапкыр Казанның бер балалар бакчасында каршыладым. Көз монда төрле кызыклы уеннар, тәмле-тәмле бүләкләр белән килде. Сабыйлар арасында үзеңне дә бала итеп тоясың. Күңелнең кайсыдыр почмагында яшеренеп яткан сабыйлык хисләре менә-менә сәхнәгә чыгар да, шул балалар арасына кереп әйлән-бәйлән уйный башлар төсле. Казанда яшәүче сеңлем Алиянең чыгышын караганда, хәтта күзләр дә яшьләнде. Сиңа чын мәгънәсендә якын булган кешенең сәхнәдәге чыгышы йөрәккә дә якын була икән ул. Хәзер сәхнәдә шигырь сөйләүче балалары өчен янып-көеп утырган әти-әниләрнең хәлен яхшы аңлыйм кебек.

Өченче тапкыр көз туган авылымның мәдәният йортында үткән кичә белән килде. Җәйне чыгып, кышка әзерләнгәндә, көзен авыл халкы гасырлардан гасырларга үзләренең уңышларын санаган, тырыш, эшчән халкы белән горурланып, аларга бәйрәм оештырган. Бусы инде Уңышлы көз! Авыл халкы тырышып тир түккән ипинең ничек җирдә шытым биреп табыннарыбызга килүе турында театраль тамаша күңелләргә кереп, ипинең кадерен тагын бер кат төшендерде.

Быел көзне өч тапкыр каршы алдым. Гомумән, көз фасылы күңелемә якын. Яфраклар белән уйнаган җил көенә күңелдә яңа шигырьләр туа, әллә нигә бер ялындырып кына караган көз кояшы да күңелгә якын. Әллә көзен дөньяга мин килгәнгә микән?

● Бәйге

# Татар телле руслар көч сынашты

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

28 ноябрь көнне Филология һәм сәнгать институтында Бишенче мәртәбә рус телле студентлар өчен татар теленнән олимпиада үткәрелде.

Быелгы чарада Татарстанның алты вузыннан – КФУ, КНИТУ, КДМУ, КДЭУ, Казан дәүләт ветеринария академиясе һәм Әлмәт муниципаль институтыннан барлыгы 55 студент катнашты. Олимпиада да рус милләте вәкилләре генә көч сынашты. Бәйге, гадәттәгечә, ике турдан торды. Беренче өлеше язмача булса, икенчесендә әңгәмә корырга кирәк. Студент билет ала да, аңа бер ситуация бирелә. Олимпиадада катнашучы «судан коры чыгарга», фикерен белдерергә тиеш.

Телдән җавап бирү өчен, әзерләнергә вакыт бирелми. Студент билетны укып, эксперт алдында шунда ук җавап бирә. Катнашучының бер мәртәбә билетны алыштыру хокукы бар.

Олимпиадада карар чыгаручы экспертлар – КФУның Филология һәм сәнгать институты укытучылары. Иң күбе 100 балл җыярга мөмкин: 80 баллны – язма өлештә, 20 баллны телдән җавап биргәндә алып була. Олимпиада нәтиҗәләрен игълан итү, җиңүчеләрне бүләкләү 21 февральдә – ФСИның туган көнендә үтәчәк.

Олимпиада башланыр алдыннан, катнашучыларны татар телен өч ай дәвамында өйрәнеп, шактый уңышларга ирешкән чит ил студентлары сәламләде. Алар - Италия, АКШ, Финляндия, Латвиядән Казанга рус телен өйрәнер өчен килеп, татар теле, тарихы, мәдәнияте белән кызыксынып киткән, бу өлкәләрне ныклап өйрәнергә керешкән яшьләр. Үзләре турында татар телендә кыскача монолог сөйләп, залда утыручыларны шаккаттырдылар.

Руслар гына түгел, чит ил вәкилләре дә татар телен өйрәнергә теләк белдерә икән, телебезнең, милләтебезнең зур киләчәге бар. Мондый олимпиадалар әлеге фикерне тагын бер кат раслый.

● Әдәп-әхлак

# Тәрбиясез булмый...

**Маргарита БАИМОВА,**
Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты

Яңа туган балалар бар җирдә дә бер төрле елыйлар. Ә менә үсеп җиткәч, аларның гадәтләре төрлесенең төрлечә. Болар барсы да - тәрбия җимешләре.

Без еш кына кешене тулысынча тәрбияле һәм әхлаклы дип ялгышабыз. Шыгрым тулы автобуста кайчак өлкән яшьтәге кешеләр басып торганда, япь-яшь, сәламәт егетләр-кызларның оялмыйча утырып барулары мине шаккаттыра. Гаять зур чиратта торган гарип яисә өлкән яшьтәге кешеләрне бик сирәкләр генә алга уздырып җибәрә. Берьюлы автобуска укудан кайтканда, бер хәлгә юлыктык. Берничә исерек егет үзара нәрсәдер бүлә алмыйча акырыша. Кондукторның берничә кисәтүенә карамастан, талашуны дәвам иттеләр. Җитмәсә, һәрбер сүз саен сүгенеп, автобуста барган кешеләргә теләсә нәрсә әйтеп баралар.

Менә автобуска өлкән яшьтәге бабай белән әби керде. Таныш түгел бабайга егетләрнең кыланышы бер дә ошамады, кисәтү ясады. Теге адәм актыклары бабайга аты-юлы белән җавап кайтарды. Бу хәлне күреп, мин бик гарьләндем. Ни кызганыч, мондый күренешләрне еш очратырга була. Без көннән-көн шушы тәрбиясезлеккә битараф калабыз.

Хәзерге яшьләрнең тәрбиясезлеге артканнан арта баруның сәбәбе дә бик гади. Күп кеше үз кызыксынулары, максатлары турында гына уйлый, барысы да каядыр ашыга. Ә балалар тәрбияләү турында берсе дә уйламый. Дөнья мәшәкатьләрен кайгыртып, бар кешегә дә ачык йөзле булу бик катлаулыдыр. Әйдәгез, иртән торгач, үзеңә-үзең, дусларыңа, туганнарыңа, үтеп баручыларга да елмаю бүләк итик, кешеләргә хөрмәт белән карыйк, без дә алардан җавап итеп елмаю алырбыз. Кешеләр көн саен шулай итсәләр, ул гадәткә керәчәк. Шулчак барыбыз да киң күңеллерәк булырбыз. Дөнья да яхшы якка үзгәрер. Минемчә, тәрбия беренче нәүбәттә кешелеклелек. Без һәр көн саен камилләшергә, халкыбызның әхлагын югарырак итәргә өлешебезне кертергә бурычлы!

**Әдәби Ат**

Бүген «Әдәби Ат» сәхифәсендә кунак бар. Шагыйрә, драматург, Башкортстанда нәшер ителгән «Тамаша» журналының мөхәррире **Лилия САКМАР** безнең студентларыбызга да шигырьләрен тәкъдим итә. Тиздән беренче юбилеен каршы алачак шагыйрәнең иҗат җимешләре яшьләр күңеленә дә үтеп керер. Ә шагыйрәне гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез! Татарстан белән Башкортстанның дуслык күпере ераkларга балкып торсын!



## Мин Кояшка китеп барам

*Мин туганда, төнне җиңеп,*
*Балкып аткан иде ал таң,*
*Тәңге шул таң нурын алып,*
*Мин Кояшка китеп барам!*

*Гомер юлым әрнү тулы –*
*Елмаерга көч-дәрт табам!*
*Сынауларга рәхмәт әйтеп,*
*Мин Кояшка китеп барам!*

*Теткәләнгән күңелемнән*
*Йөрәгемә ал кан тама –*
*Кан төсе – ул таң төсе дип,*
*Мин Кояшка китеп барам!*

*Дусларымның кулларыннан*
*Төзәлә бит һәрбер ярам,*
*Якыннарым фатихасы –*
*Мин Кояшка китеп барам!*

*Изгелегем – сезгә бүләк!*
*Биргән саен күбрәк алам.*
*Иң бәхетле кеше мин ул –*
*Мин Кояшка китеп барам!*

*Яшәү серен, тормыш ямен*
*Күңелеңнән эзләп кара!*
*Телисеңме, киттек бергә –*
*Мин Кояшка китеп барам!*

## Мин иремне көтәм әшеннән

*Дөнья мәшәкатен читкә куеп,*
*Баллы-майлы икмәк пешерәм.*
*Җылы коймак, итле токмач белән*
*Мин иремне көтәм эшеннән.*

*Күперерп кенә пешә икмәгем дә,*
*Самавырым көйли җай гына.*
*Чәйнегем дә күптән түргә узган*
*Борынынннан чыга пар гына.*
*Ялан исе аңкып китсен әйдә,*
*Мәтрүшкә дә бераз төшерәм.*
*Барсы да бар.*
*Ә, юк, җитми икән,*
*Мин иремне көтәм эшеннән!*

*Тамчы шатлыклардан бәхет җыям –*
*Яшәми бит мәңге кешеләр,*
*Гади көннәремнән бәйрәм ясап,*
*Мин иремне көтәм эшеннән!*

## Тынма, яңгыр!

*Тынма, яңгыр, болытларны*
*Таратырлык җилләр юк.*
*Рәнҗетелгән күңелемне*
*Юатырлык телләр юк.*

*Тынма, яңгыр, гашыйкларның*
*Чәчләреннән иркәлә.*
*Аяз хисләремне чылат*
*Болытсыз бер иртәдә.*

*Тынма, яңгыр, әрләсеннәр*
*Яуган өчен туктамый,*
*Күңелемнең болытларын*
*Таратыр җил юк һаман.*

*Тынма, яңгыр, икәүләшеп*
*Серләшикче тын гына.*
*Күңелләрдә калсын сөю,*
*Калсын бары җыр гына...*

## Әниемә әни буласым килә

*Әниемә әни булу теләк,*
*Бәү итәсем килә шым гына,*
*Кочагыма алып, әкият сөйләп,*
*Ял иттерим дөнья шавыннан...*

*Әни, сиңа әни булыйм әле,*
*Итәгемә генә утыртып,*
*Алларыңа тәмле ризык тезеп,*
*Чәй ясыймчы, касә тутырып.*

*Җил-җилпенгән гаүдән сыйпый-сыйпый,*
*Юандырыйм әле баладай.*
*Ничек түзим соң мин, ефәк кебек*
*Йомшак чәчләреңне тарамый?!*

*«Үзем!» – димә, ял ит, әни генәм,*
*Без дә бала идек, аңлыйм мин.*
*Әни, сиңа әни булыйм әле –*
*Кил, цыбимче сырлы маңгаең!*

## Мәл

*Күңелемнең чыңлап елаганы,*
*Йөрәгемнең әрнеп типкәне, –*
*Кояш эретерлек мәхәббәтнең*
*Хыялларны ташлап киткәне.*
*Өмет кыялары уалганы,*
*Сүз-бозлардан хисләр туңганы,*
*Наз сулышын*
*Күңел сараемнан*
*Әрсез җилләр шашып куганы.*
*Күзләремнән яшь чыкмаган мәлем,*
*Авызымнан зарым чыкмаган!*
*Димәк, мин яшимен!*
*Тамырларым*
*Черемәгән әле, нык һаман!*




**Белдерү**

### Хөрмәтле укучыларыбыз!

2012 елның 25 ноябреннән V Бөтенроссия **«Илһамлы каләм» әдәби әсәрләр конкурсы башланды.** Бирedә Татарстанда, Россиянең төрле төбәкләрендә һәм чит илл әрдә яшәүче 9-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Татар телендә иҗат ителгән эшләрне (поэзия, проза, драматургия, публицистика) ilhamkalam@mail.ru адресына юлларга кирәк. I тур 2013 елның 15 мартына кадәр дәвам итә. Тулырак мәгълүматны kpfu.ru сайтыннан карый аласыз. Элемтәләр өчен телефон 8-965-590-89-29.

**Кети-мети**

Татар филологиясенә укырга керүчегә сорау биреләр:
– Тукайны беләсеңме?
– Юк.
– Җәлилне беләсеңме?
– Юк.
– Такташны беләсеңме?
– Юк.
– Алайса икеле.

Чыккач абитуриентны иптәшләре урап ала:
– Йә ничек? Бирә алдыңмы?
– Әй, анда танышларың булса гына алалар икән.

***

– Сиңа туган көнеңә нәрсә бүләк иттеләр?
– Күрәсеңме, тәрәзәдән Лексус күренеп тора.
– Әйе.
– Нәкъ шуның төсендәге түбәтәй!

**Шигъри башваткыч**

## Суыткыч иясе

**Ринат НУРУЛЛИН**

*Йорт иясе булган кебек,*
*Бар суыткыч иясе.*
*Очратканыгыз булгандыр*
*Бәлки сез дә берәрсен.*

*Утыра ул суыткычның*
*Иң салкын киштәсендә.*
*Бик уңайлы сизә үзен,*
*Капланса да бәс белән.*

*... Бүген хәлләр гел башкача –*
*Суыткычта эри боз,*
*Героебыз тирләп-пешеп,*
*Төзеп маташа ребус.*

*Ребустагы һәр цифрны*
*Хәреф белән томалый,*
*Ял иткән вакытларында*
*Татлы туңдырма ялый.*

*Эше уңай баруына*
*Шат суыткыч иясе,*
*Сыр кисәгенә сырлады:*
*«БӘС + БӘС = ЭССЕ».*

*– Суыткыч иясе юк! – дип*
*Аяк чалма хыялга,*
*Ребусын чишкән вакытта*
*Син дә туңдырма яла.*

**!** Алдагы санда чыккан башваткычның җавабы: 376 x 376 = 141376.

Бу юлы «Альпинист үрмәкүчләр» Роберт МӘННАНОВка насыйп, ләкин алдагы саннарда җиңүчеләр өлгеррәк булып чыкты. Робертка гомуми ярышта 5 балл бирелә. Илмир Вәлиев 29 балл белән әлегә беренчелекне саклап калды. Алинә Ганиева – 28, Руфинә Габдрахманова – 18, Фәйрүзә Фатыйхова – 8, Гөлнара Габдуллина – 7, Зилә Сафиуллина – 7, Алмаз Нурмөхәммәтов – 5 бал туплады. Ун башваткычтан соң лигада беренче өчлеккә керүчеләрне бүләкләр көтә! Ә Ринат Нуруллин китабы һәр атна саен иң өлгер студентка бирелә! Җавапларны безнең е-майлга җибәрергә кирәк.


DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.